**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО**
**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Первомайская ул., д.39, г. Лаишево, 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ**
**РАЙОН СОВЕТЫ**

Беренче май ур., 39 нчы йорт, Лаеш ш., 422610
Тел: 8 (84378) 2-51-51
Факс: 8 (84378) 2-55-55
e-mail: Sovet.Laishevo@tatar.ru

**2024елның 20 мае** **39-РС номер**

# КАРАР

**Лаеш шәһәре Башкарма комитеты балансында булган муниципаль милекне Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә түләүсез файдалануга тапшыру турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Лаеш муниципаль районы Советының 2010 елның 23 июлендәге 24 номерлы карары белән расланган Лаеш муниципаль районы муниципаль мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турындагы нигезләмәгә таянып, Лаеш муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. ТР, Лаеш муниципаль районы, Лаеш шәһәре, М. Ульянова урамы, 54 йорт адресы буенча урнашкан 33,1 кв. м мәйданлы бинаны (кушымтага ярашлы) биш елга Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә (алга таба - Учреждение) түләүсез файдалануга тапшырырга.
2. Учреждениегә бер ай эчендә Лаеш шәһәре Башкарма комитеты белән мөлкәткә түләүсез файдалану турында килешү төзергә һәм аны Лаеш муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасына килештерү өчен тәкъдим итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек комиссиясенә йөкләргә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы рәисе** **И.Ф. Зарипов**

*Лаеш муниципаль
районы
Советының 2024 елның 20.05
39-рс номерлы карарына
Кушымта*

Россия Федерациясе Тикшерү комитетыныңТатарстан Республикасы буенча Тикшерү идарәсенә түләүсез файдалануга тапшырыла торган муниципаль милек исемлеге

| N т/б | Инвентарь һәм кадастр номеры | Объектның исеме һәм характеристикасы (катлылык, төзелеш материалы һ. б.) | Урыны (адрес) | Саны | | | | Кабул итү елы (сатып алу) | Баштагы бинаның торгызу бәясе, мең сум. | Тузу | | Калдык бәясе, мең сум. |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Данә яки погон метры | Мәйданы, кв.м | | | | | % | сум. | |
| | | | | | Техник паспорт буенча гомуми | файдалы | Өстәлгән төзелеш. | | | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 |
| 1 | и:01010002 | Административ бинаның беренче катындагы бина | Лаеш шәһәре, М. Ульянова ур., 54 | 1 | | 33,1 | | 1968 | 69.0 | 100 | 69.0 | 0 |